МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.10.2023 Казан шәһәре № 216

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль

законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы указын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә:

2.1. Әлеге боерык белән Министрлыкның Вазыйфалар исемлегенә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен таныштырырга.

2.2. Эштән киткәндә Министрлыкның Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы нигезләмәләрен аңлатырга.

2.3. Әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.

2.4. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә әлеге Боерыкның 1 пункты нигезендә расланган вазыйфалар исемлеген расланган көннән өч көн эчендә тапшырырга, ә аннан соң, аңа үзгәрешләр керткәндә, үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә вазыйфаларның төгәлләнгән исемлеген тапшырырга.

2.5. Әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталында Министрлык сайтындагы «Коррупциягә каршы көрәш» бүлегендә урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 10 ноябрендәге 442 номерлы;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2021 елның 10 ноябрендәге 442 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 10 ноябрендәге 380 номерлы;

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәрләренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 10 ноябрендәге 442 номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында» 2023 елның 9 мартындагы 56 номерлы.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары –**
**министр** **М.Р.Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2023 елның 17 октябрендәге
216 номерлы боерыгы белән
расланды

## Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – 1 берәмлек;

Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры – 1 берәмлек;

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – Социаль-икътисадый мониторинг департаменты җитәкчесе – 1 берәмлек;

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары – 4 берәмлек.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы икътисад министры ярдәмчесе – 1 берәмлек.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшләр идарәчесе – 1 берәмлек;

юридик бүлек җитәкчесе – 1 берәмлек;

финанс исәбе һәм хисаплылык бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

Җайлау йогынтысын бәяләү һәм конкуренцияне үстерү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

инвестиция климатын үстерү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

инновацияләрне үстерү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

инвестиция сәясәте һәм проектларга икътисадый анализ бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

җитештерү куәтләрен үстерү һәм урнаштыру бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

капитал салу бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

проект эшчәнлеге һәм илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны координацияләү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны координацияләү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

дәүләт мәгълүмат системалары белән эшләү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

дәүләт идарәсен камилләштерү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

лицензияләү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

контроль һәм күзәтчелек эшчәнлеген камилләштерүне координацияләү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

макроикътисадый фараз бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

стратегик үсеш бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

индикатив идарә бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

эшчәнлек бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

мәгълүматлаштыру бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

эшчәнлекне һәм сатып алуларны тәэмин итү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры урынбасары – 1 берәмлек;

мобилизацияле әзерлек секторы мөдире – 1 берәмлек;

кече һәм урта эшкуарлык базарларын үстерү секторы мөдире – 1 берәмлек;

эшкуарлыкка инфраструктура ярдәме секторы мөдире – 1 берәмлек;

социологик сораштырулар секторы мөдире – 1 берәмлек;

консультация-методика секторы мөдире – 1 берәмлек;

юридик бүлек җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

финанс исәбе һәм хисаплылык бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

инновацияләрне үстерү бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

капитал салу бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

проект эшчәнлеге һәм илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны координацияләү бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

дәүләт идарәсен камилләштерү бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

макроикътисадый фараз бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

стратегик үсеш бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

эшчәнлекне һәм сатып алуларны тәэмин итү бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

Мәгълүмат ресурслары, икътисадый анализ һәм социаль үзгәрешләрне тикшерү идарәсе җитәкчесе – 1 берәмлек;

Эшкуарлыкны үстерү идарәсе җитәкчесе – 1 берәмлек;

сәнәгать паркларын үстерү бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

эшкуарлык үсешен анализлау бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

мәгълүмат ресурслары һәм технологияләр бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

мәгълүмати-аналитик бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәлен мониторинглау бүлеге җитәкчесе – 1 берәмлек;

сәнәгать паркларын үстерү җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

мәгълүмат ресурслары һәм технологияләр бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

мәгълүмати-аналитик бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

муниципаль берәмлекләрнең һәм предприятиеләрнең социаль-икътисадый хәлен мониторинглау бүлеге җитәкчесе урынбасары – 1 берәмлек;

юридик бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 берәмлек;

юридик бүлекнең әйдәп баручы консультанты – 2 берәмлек;

икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек;

инвестиция сәясәте һәм проектларга икътисадый анализ бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 3 берәмлек;

инвестиция сәясәте һәм проектларга икътисадый анализ бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;

инновацияләрне үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;

эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;

финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 1 берәмлек;

финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;

сәнәгать паркларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 берәмлек;

сәнәгать паркларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;

кече һәм урта эшкуарлык базарларын үстерү секторының әйдәп баручы консультанты – 1 берәмлек;

Җайлау йогынтысын бәяләү һәм конкуренцияне үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе – 2 берәмлек.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече – 3 берәмлек;

финанс исәбе һәм хисаплылык бүлегенең әйдәп баручы белгече – 5 берәмлек;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече – 1 берәмлек;

эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы белгече – 1 берәмлек;

финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларын гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы белгече – 1 берәмлек;

сәнәгать паркларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече – 1 берәмлек;

эшчәнлекне һәм сатып алуларны тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече – 1 берәмлек.

7. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече – 1 берәмлек;

эшчәнлекне һәм сатып алуларны тәэмин итү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече – 1 берәмлек.